**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.01.2026 № 11

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан халыкка күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Дәүләт төзелешенең «торак-коммуналь хезмәтләргә халыкның түләү сәләтен исәпләү методикасын раслау турында» 1998 елның 11 ноябрендәге 12 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан 2025 елның 24 декабрендәге 159 номерлы шәһәр мунчасы буенча чыгымнар үсеше хисабын карап чыкканнан соң, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан халыкка күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифларны әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Нурлат муниципаль районы Башкарма
комитетының 2026 елның 12 гыйнварындагы
11 номерлы карарына кушымта
Нурлат муниципаль районы Башкарма
комитетының 2026 елның 12 гыйнварындагы
11 номерлы карары белән
**РАСЛАНДЫ**

# «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләре тарифы

| №№ тс | Мунча хезмәтләре күрсәтү, категорияләр | Юыну вакыты, бер сәгать | Хезмәтләр бәясе, сум. |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Пенсионерлар һәм инвалидлар пенсия таныклыгы һәм (яисә) пенсия билгеләү турында белешмә булганда | 1 | 325,00 |
| | | 2 | 510,00 |
| 2 | Эшләүче халык | 1 | 380,00 |
| | | 2 | 680,00 |
| 3 | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге ата-аналары (туганнары) белән мунчага йөрүче балалар | | 190,00 |
| | **Хезмәтләрне түләүсез күрсәтү** | | |
| 1 | Бөек Ватан Сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга тиңләштерелгән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә | | |
| 2 | Нурлат муниципаль районы территориясендә яшәүче пенсионерларга һәм инвалидларга, пенсионерлар һәм инвалидлар декадасында | | |
| 3 | Әти-әниләре (туганнары) белән мунчага йөрүче 3 яшькә кадәрге балаларга | | |
| | **Килүләр графигы** | **10:00 - 18:00** | |
| | | | |
| | **Дүшәмбе** | **Санитар көн** | |
| | **Сишәмбе** | **Ял көне** | |